**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**БОЕРЫГЫ**

12.04.2023 № 147

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы каршындагы Татарстан Республикасы судьялары квалификация коллегиясендә җәмәгать вәкиллегенә кандидатларны алдан сайлап алу комиссиясе төзү турында» боерыгына үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасы каршындагы Татарстан Республикасы судьялары квалификация коллегиясендә җәмәгать вәкиллегенә кандидатларны алдан сайлап алу комиссиясе төзү турында» 2002 елның 22 октябрендәге 66 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Боерыгына (Татарстан Республикасы Президентының 2004 елның 18 октябрендәге 195 номерлы, 2006 елның 20 ноябрендәге 282 номерлы, 2008 елның 16 октябрендәге 264 номерлы, 2010 елның 13 августындагы 263 номерлы боерыклары, Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 24 июлендәге ПУ-617 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 24 маендагы 235 номерлы, 2015 елның 14 февралендәге 129 номерлы, 2016 елның 24 ноябрендәге 681 номерлы, 2017 елның 21 августындагы 511 номерлы һәм 2020 елның 20 ноябрендәге ПУ-768 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) атамада «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы» сүзләренә алмаштырырга;

преамбулада «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы» сүзләренә алмаштырырга;

комиссия әгъзалары вазыйфалары атамаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

А.Н. Беловның – «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты җитәкчесе»;

Л.Ю. Глухованың – «Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт-хокук идарәсе башлыгы»;

Д.А. Рословның – «Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт-хокук идарәсе ярлыкау мәсьәләләре секторы мөдире»;

2 пунктта «Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт-хокук идарәсе» сүзләренә алмаштырырга.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**